ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

20.03.2020 г.Лениногорск № 32

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 29 ноябрендәге 146 номерлы «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 04 апрелендәге 32 номерлы редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында «2009 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 29 ноябрендәге 146 номерлы карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «н» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның «м» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) әлеге Федераль законда каралган контрактны үтәүгә, үзгәртүгә карата таләпләрне үтәү, шулай ук контракт шартларын үтәү, шул исәптән

куелган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килү-килмәве өлешендә, контракт шартларын үтәү»;

3 пунктның «л» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның «г "һәм «д" пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү һәм нигезләү, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактның бәясе, товар берәмлегенең, эш, хезмәт күрсәтүләр берәмлегенең башлангыч бәясе, товар берәмлекләренең бәясенең башлангыч суммасы, эш, хезмәт күрсәтүләр бәясенең дөреслеген;

сатып алуларның идентификацион кодлары турындагы мәгълүматның туры килүе һәм сатып алуларның план-графикларында булган мәгълүматны гамәлгә ашыру өчен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттырмау, сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләр, тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләре, сатып алуларда катнашучылар тарафыннан контрактлар төзелгән контрактлар реестрында җибәрелгән контрактлар проектлары шартлары;».

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы С. В. Тимаков

И. Р. Хәйбрахманов
5-44-72